КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 5 июль г.Казань № 639

2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча республика ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу kарарга теркәлгән 2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган

оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча республика ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 2.13 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 5 июль, 639 нчы
карары белән расланды

2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча республика ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану хакында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә һәм 2022 елда гражданлык җәмгыятен үстерүдә катнашучы, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендә социаль әһәмиятле проектларны һәм проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы грантларын бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен «Коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмаларга ярдәм күрсәтү буенча республика ресурс үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына (алга таба – грант операторы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән субсидия (алга таба шул ук эзлеклелектә – проект, грантлар бирү буенча конкурс, субсидия) бирү максатын, шартларын һәм механизмын билгели.

1.2. Субсидия бирү максаты – грантлар бирү буенча конкурслар үткәрүне оештыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү.

1.3. Субсидия бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен 2022 елга субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

1.4. Бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка каралган Татарстан

Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Министрлык.

1.5. Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

1.6. Финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган грантлар бирү өчен конкурслар үткәрүгә бәйле чыгымнар юнәлешләренә түбәндәгеләр керә:

штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү;

штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр;

гражданлык һәм хокук характерындагы шартнамәләр буенча җәлеп ителә торган затларның хезмәте өчен түләү;

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү;

чит оешмаларның һәм физик затларның хезмәт күрсәтүләре өчен түләү (юридик һәм бухгалтерлык хезмәтләре, фотога һәм видеога төшерү);

почта һәм курьер чыгымнары;

чыгым материаллары сатып алу;

типография чыгымнары;

банк хезмәте күрсәтү;

транспорт чыгымнары (шул исәптән ягулык-майлау материалларына);

командировка чыгымнары өчен түләү;

грантлар бирү буенча конкурсларга тәкъдим ителгән проектларга экспертиза үткәргән өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

проектларны гамәлгә ашыру мониторингын оештырган өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

төгәлләнгән проектларның ирешелгән эффектларына бәйсез тышкы бәяләүне оештырган өчен хезмәт күрсәтүләргә түләү;

массакүләм мәгълүмат чараларында грантлар бирү буенча конкурслар үткәрү барышын һәм нәтиҗәләрен яктырту;

мәгълүмати-технологик хезмәт күрсәтүләр (электрон-цифрлы имза алу, бухгалтерлык һәм склад исәбе системасы, болыт саклагычында урын сатып алу, техник яктан тәэмин итү, сервислар арендалау, программалар кую һәм шәхси компьютерларга хезмәт күрсәтү);

элемтә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре хезмәтләре өчен түләү.

## II. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Субсидия грант операторының субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айның 1 нче көненә түбәндәге таләпләргә туры килү шарты белән бирелә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар,

процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау (2022 елда салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш;

үзгәртеп оештыру (грант операторына башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максат өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

2022 елда Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлар тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмау.

2.2. Субсидия алу өчен грант операторы түбәндәге документларны кәгазьдә Министрлыкка 420021, Казан шәһәре, Мәскәү урамы, 55 нче йорт адресы буенча йомыш белән җибәрелгән кеше аша тапшыра яки почта аша җибәрә:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча грант операторының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан кул куелган, мөһере сугылган грант операторы турындагы мәгълүматны, грант операторы турындагы башка мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын үз эченә алган субидия бирүгә гариза (алга таба – гариза);

грант операторының гамәлгә кую документлары күчермәләре;

грант операторының уставы һәм аңа кертелә торган үзгәрешләр күчермәсе (булганда);

чыгымнарның финанс-икътисадый нигезләве, шул исәптән планлаштырыла торган чыгымнар юнәлешләре калькуляциясе бирелгән, аларның күләмнәре нигезләнә торган мәгълүмат, шулай ук алу чыганагы күрсәтелгән субсидия күләменең җентекле исәп-хисабы (счетлар, товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин

итүчеләрнең коммерция тәкъдимнәре, җитештерүченең бәяләре турында, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турында мәгълүмат);

грант операторы тарафыннан «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 2 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә үз эшчәнлеген дәвам итү турындагы мәгълүматны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә бирүне раслый торган документ күчермәсе;

грант операторының җитәкчесе кул куйган һәм грант операторының мөһере сугылган, аның бу Тәртипнең 2.1 пункты таләпләренә туры килүен раслый торган ышаныч хаты.

2.3. Грант операторы үз инициативасы белән түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон формада бирү форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20@ номерлы боерыгы белән расланган форма буенча бирелгән салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәрен түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү йөкләмәсен үтәве турында салым органының белешмә кәгазе.

Бу пунктның икенче – өченче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

2.4. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

документлар, бозып төзәтүләр, төзәтүләр, төзәтмәләр (грант операторының җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан кул куелган һәм мөһер сугылган төзәтүләрдән тыш) ясамыйча, билгеләнмәгән кыскартмалар һәм ике төрле мәгънәдә аңлашыла торган формулировкалар кулланмыйча, техник чаралар ярдәмендә әзерләнергә тиеш;

документларның күчермәләренә грант операторының җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан кул куела;

гаризаның һәм аңа теркәлә торган документларның барлык битләре номерланган булырга тиеш;

гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тегелергә һәм грант операторының җитәкчесе яки вәкаләтле зат тарафыннан кул куелырга һәм гаризаның арткы битендә битләрнең гомуми саны күрсәтелеп мөһер сугылырга тиеш.

Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен грант операторы Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

2.5. Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар Министрлык тарафыннан алар

кергән көндә, гариза керү датасы һәм вакыты күрсәтелеп, заявкаларны теркәү журналында теркәлә. Министрлык гариза теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көн эчендә аның бу Тәртип таләпләренә туры килү-килмәвен карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

2.6. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 2.2 пунктында каралган документларның тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмавы);

грант операторы тарафыннан бирелгән документларның бу Тәртипнең 2.4 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

грант операторының бу Тәртипнең 2.1 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

грант операторы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмау факты билгеләнүе;

бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

Субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык әлеге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә грант операторына, баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп, хәбәрнамә җибәрә.

2.7. Субсидия бирү Министрлык тарафыннан килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү грант операторы һәм Министрлык арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә төзелә.

Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә килешү проекты Министрлык тарафыннан Министрлыктан килешү проекты алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көн эчендә грант операторы адресына аңа имза кую өчен җибәрелә.

Министрлык тарафыннан килешүгә грант операторыннан аның тарафыннан имза куелган килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә имза куела.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидияне күчерү сроклары һәм тәртибе;

грант операторы тарафыннан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисаплар, өстәмә хисаплылык (кирәк булганда) кертү сроклары һәм формалары;

грант операторы һәм Министрлык арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү төзү шартлары һәм тәртибе;

субсидияне кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 2.15 пунктында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда әлеге акчага ихтыяҗ булу яки әлеге акчага ихтыяҗ булмаганда аларны кире кайтару турында карар кабул ителгәндә, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган шарт;

бу Тәртипнең 2.14 пунктында билгеләнгән формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен куллану очракларын күздә тоткан шартлар;

грант операторының, грант операторы белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә грант операторының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;

грант операторы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр;

грант операторы, шулай ук грант операторы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затлар тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасы (югары технологияле импорт җиһазын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында нигезләмәләр;

бу Тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе).

2.8. Субсидия бирүнең нәтиҗәләре:

Татарстан Республикасында гражданлык җәмгыяте үсеше турында аналитик мәгълүмат әзерләү – кимендә бер;

грантлар бирү конкурсы үткәреләчәк «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында профилактик эшләр үткәрү – кимендә ике;

массакүләм мәгълүмат чараларында (яки социаль челтәрләрдә) грант операторы эшчәнлеге һәм грантлар бирү конкурсларын үткәрү турында кимендә биш мәгълүмат бирү характерындагы хәбәрләр бастырып чыгару;

коммерциягә карамаган оешмалар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында грантлар бирүгә заявкалар формалаштыру буенча консультацияләр

оештыру – кимендә 60 консультация;

экспертлар өчен «Грант конкурсы» автомат мәгълүмат системасында коммерциягә карамаган оешмаларның грантлар бирү турындагы заявкаларына экспертизалар үткәрү буенча консультацияләр оештыру – кимендә 20 консультация.

Бу пунктта күрсәтелгән нәтиҗәләргә ирешү срогы – 2022 елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

2.9. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = З_1 + З_2 + ... + З_n + Z_1 + Z_2 + Z_3,$$

монда:

$З_1$, $З_2$, ..., $З_n$ – бу Тәртипнең 1.6 пунктындагы дүртенче, алтынчы – унберенче, унөченче – унсигезенче абзацларында күрсәтелгән юнәлешләр буенча Министрлык тарафыннан бердәй (бертөрле) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүчеләрнең бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарында, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында һәм махсус әдәбиятта (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) булган бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт чагыштырма базар бәяләре (базар анализы) ысулы белән билгеләнә торган чыгымнар суммасы;

$Z_1$ – штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен хезмәткәрләрнең исәпләнә торган саныннан, исәпләнә торган вазыйфаи окладлардан, премияләрдән, шулай ук расланган штат расписаниесе нигезендә Россия Федерациясе законнарында каралган башка түләүләрдән чыгып билгеләнә торган түләү чыгымнары;

$Z_2$ – салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләү чыгымнары;

$Z_3$ – командировка чыгымнары өчен Россия Федерациясе законнарында каралган чыгымнарны каплау нормаларыннан чыгып билгеләнә торган түләү чыгымнары.

2.10. Министрлык килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 10 көн эчендә грант операторының Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына субсидия күчерә.

Грант операторы субсидия акчасының керүе һәм тотылуы буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

2.11. Грант операторы Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән, килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны башкару турында хисап. Әлеге хисап квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган 10 нчы эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә, IV квартал өчен хисап 2023 елның 31 гыйнварына кадәр тапшырыла;

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән, килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү

нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап. Әлеге хисап квартал саен хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча бирелә, IV квартал өчен хисап 2023 елның 31 гыйнварына кадәр тапшырыла;

килешүдә каралган срокларда һәм формалар буенча өстәмә хисаплылык (килешүдә шулай билгеләнгәндә).

2.12. Министрлык грант операторы тарафыннан тапшырылган хисапларны алар алынган көннән 15 эш көне эчендә тикшерә.

2.13. Министрлык грант операторының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268[1] һәм 269[2] статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгалләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

2.14. Субсидия грант операторы тарафыннан Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

грант операторы тарафыннан субсидия бирү шартлары һәм тәртибе бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча да – тулы күләмдә;

субсидия алу өчен грант операторы тарафыннан дөрес булмаган (тулы булмаган) белешмәләр һәм документлар тапшырылган очракта – тулы күләмдә;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап, өстәмә хисаплылык (килешүдә мондый билгеләнгәндә) тапшырылмаган очракта – тулы күләмдә.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, грант операторы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

2.15. Субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлык тарафыннан, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән очраклардан тыш, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Хисап финанс елында файдаланылмаган акчаны бу Тәртипнең 1.2 пунктында күрсәтелгән максатка җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, грант операторы, 2023 елның 31 гыйнварыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка мондый ихтыяҗны нигезләп мәгълүмат бирә.

Министрлык, грант операторыннан бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны алган көннән 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, бюджет законнары нигезендә грант операторының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу яки булмау турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан грант операторының агымдагы финанс елында субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмый калган өлешен җибәрүгә ихтыяҗы булу турында карар кабул ителгән очракта, Министрлык һәм грант операторы арасында мондый карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнелә торган өч көн эчендә өстәмә килешү төзелә.

2.16. Грант операторы тарафыннан бу Тәртипнең 2.14 һәм 2.15 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнелә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

2.17. Субсидияне нәтиҗәле файдалануны контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.